УДК 09.930

***Ф.Г. Фәйзуллина***

# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР ТУРЫНДА

Комплексная экспедиция по изучению языковых особенностей, фольклора и культуры татар Пензенской области была организована Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в 2022 г. В данной статье представлен обзор результатов экспедиции по археографии, которая проводилась с целью выявления и сбора памятников письменности.

**Ключевые слова:** татары Пензенской области, археография, экспедиция, памятники письменности.

A comprehensive expedition to study the linguistic features, folklore and culture of the Tatars of the Penza region was organized by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2022. This article presents an overview of the results of the expedition on archeography which was carried out with the aim of identifying and collecting written monuments.

**Keywords:** Tatars of the Penza region, archeography, expedition, written monuments.

Татар халкы тарихында Пенза өлкәсе аерым урын алып тора. Татарлар Пенза өлкәсе территориясендәге иң борынгы халыклар рәтенә керә һәм нәкъ менә алар, X гасырдан башлап XVII гасырга кадәр, бу территориядә төп тарихи көч булган дияргә мөмкин [Зюзин; Саляев, с. 122–126].

Пенза өлкәсе татарларының тарихы бик бай һәм кызыклы. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедицияләрнең чираттагысы шушы өлкәдә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен, тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышланган иде. Әлеге өлкә элегрәк тә тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп иткән. 1958 елда институт тарафыннан оештырылган фольклор җыю буенча фәнни экспедиция шушы өлкәнең татарлар яшәгән Белинский (Кутеевка авылы), Каменка (Кикин, Кабылкин, Мачали авыллары), Соснобор (Индерка авылы), Неверкин (Мазарлы авылы), Лопатин (Вершаут, Иске Карлыган авыллары), Кузнецк (Ялгаш авылы) кебек районнарына үткәрелгән була [Татар халык иҗаты, б. 320].

2022 елда экспедициябез Пенза өлкәсенең Каменка, Белинский, Пачелма, Вадинск һәм Спас районнарындагы 14 татар авылына оештырылды. Россия куенындагы Пенза өлкәсендә гомер кичерүче милләттәшләребез, татар дигән исемгә тугры калып, горур гына яшәп яталар. Алар, олысы да, кечесе дә, рәхәтләнеп, авыз тутырып, үзләренә хас татар телендә сөйләшәләр. Һәм шушы сыйфатлары белән үзләренә җәлеп итеп торалар.

Сәяхәтебез Каменка районының Кикин авылыннан башланды. 1690 елда, риваятьләр буенча, Арслан Акҗигитов тарафыннан нигез салынган әлеге авыл – тарихи «Алты авыл»ның иң зурысы («Алты авыл» – Пенза өлкәсенең алты татар авылын берләштергән атама). Үз эшләренең белгечләре булган – мәктәпнең Тарихи-туган якны өйрәнү музее директоры Равилә Билал кызы Девлекамова һәм татар теле укытучысы Равилә Фәрит кызы Баткаеваның Кикин һәм «Алты авыл» тарихы турындагы этрафлы чыгышлары, мәктәп кысаларына гына сыймыйча, урман уртасында искиткеч матур табигать кочагындагы милли герой Акҗигитов Арслан Палкай улы кабере янында да дәвам итте. Эзләнүләребезнең нәкъ шушы тарихи авылдан башланып китүе бездә алда барачак авылларга карата зур кызыксыну уятты.

Халык үзенең тарихы белән кызыксына, өйрәнә, мәгълүмат туплый. Ә тарихыбыз тирәнрәк ачылсын, мәдәни мирасыбыз баесын өчен, галимнәр һәрвакыт халык ярдәменә мөрәҗәгать итә.

Татар халкы элек-электән китапка хөрмәт белән караган. Аларның һәркайсы саклык белән генә кадерләп тотылган. Халкыбызның тарихын саклаган язма ядкәрләр буыннан буынга тапшырылып килгән. Шуңа күрә халык кулында сакланып калган әлеге рухи мирасны өйрәнү аеруча зур әһәмияткә ия. Комплекслы экспедицияләрнең төп максатларыннан берсе дә – нәкъ менә борынгы басма китапларны, кулъязмаларны барлау, туплау.

Заманында дүрт мәчет булган Кикин авылы уртасында бүген дә заманча төзелгән (2009 елда) ике катлы зур «Айшә, Маһирә» үзәк мәчете нурлар чәчеп утыра. Имам Илдус хәзрәт Шамил улы Такташев сүзләренә караганда, авылда иске китапларны укучы кешеләр инде калмаган. Ләкин авыл халкы, электән үк гарәп язулы китапларга бик игътибарлы һәм хөрмәт белән караучы буларак, үзләре укый белмәгәнлектән, кулларында булган истәлекләрне мәчеткә саклауга тапшырганнар.

Күпсанлы Коръән китапларын исәпкә алмаганда, мәчеттә гарәп язуында 30 га якын төрле эчтәлектәге басма китаплар барлыгы ачыкланды. Аларның күпчелеген дини-дидактик басмалар тәшкил итә. «Мөхәммәдия», «Һәза китаб әт-тәҗвид» (Казан, 1876), «Һәфтияк шәриф» (Казан, 1889), «Алты бармак» (Казан, 1902), «Вакты сәхәр китабы» (Казан, 1908), «Әзкяр әс-салят» (Казан, 1917), «Бәдәвам» һ. б. шушы исемлектән. Алар арасында дөньяви белем бирә торганнары да очрады. Мәсәлән, Тыйб китабы, Физика китабы, Фикъһ китабы, «Балаларга кыйраәт», «Ана теле», «Гөл бакчасы» (шигырьләр китабы) һ. б. шундыйлардан. Кызганычка, күбесенең я башы, я ахыры юк, яки шундый китап булганлыгын дәлилли торган аерым битләре генә калган. Мәчеттәге әлеге байлыкның һәрбер битенә игътибарлы булып, кулдан кичереп чыгарга тырыштым. Авылдагы кешеләрнең гарәпчә язмаларга бик сакчыл караганлыклары күренеп тора. Араларында аерым битләрдә язылган мәет өстендә укыла торган «Балага ананың васыяте», 40 көнендә рухларга Коръән багышлау һәм шулай

ук аерым кульъязма догалар да очрады. Китаплар арасыннан килеп чыккан тагын бер кәгазь аеруча игътибарга лаек. Ул – 1896 елда булган никахлар язылган Метрикә кенәгәсенең аерым бите. Әлеге биттә, 3 нче сан белән, 28 февральдә Пенза губернасы Чембар өязенең Кикин авылының Хөсни Рәхмәтулла углының 24 яшьлек кызы Шәрифә белән шул ук өязнең Кабылкин авылының солдаты 25 яшьлек Шәрифҗан Мөхәммәдгали углының никахы һәм, 5 нче сан белән, 29 мартта Пенза губернасы Чембар өязе Кикин авылының Әхмәдҗан Габделхаликъ углының 20 яшьлек кызы Таһирә белән шул ук авылның солдаты 26 яшьлек Муса Мөхәммәдрәхим улының никахлары теркәлгән.

Авыл кешеләрендә (Конеева Гүзәл Исхак кызы, (1948 елгы) сакланган «Гарәп әлифбасы», «Дин нигезләре» (намаз тәртипләре), «Мәүгазә дәрел нәсыйхин» (вәгазьләр) китаплары тагын бер кат авыл халкының укымышлы һәм дингә омтылышы булганлыгына дәлил булып торалар. Биредә башкача булырга мөмкин дә түгел, чөнки Кикин – атаклы Бигиевләрне биргән авыл. Татар әдәбиятының күренекле вәкиле Заһир Бигиев (1870–1902), әтисе ахун булып билгеләнеп, гаиләсе белән Ростов-Донга күченергә җыенып йөргән вакытта Кикиндә дөньяга килгән. Авыл кешеләре сүзенә караганда, бүгенге көндә алар нигезендә шул нәселнең дәвамчылары яши.

«Алты авыл»ның иң кечкенәсе Тәләтен авылы (Каменка районы) безне бик тыйнак кына каршы алды. Авыл халкы белән аралашканда, авылда әби-бабаларыннан калган иске китапларны, язмаларны кабергә илтеп күмү кебек аяныч хәлләр дә булганлыгы турында ишетергә туры килде. Шулай да үзлегеннән гарәпчә өйрәнгән, заманында абыстай булган Рушания Сабирҗан кызы Такташева (1939 елгы) өендә «Кыйссаи Сәйфелмөлек» (Казан, 1807), «Ике үксез» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» кебек басма китаплар һәм «Догаи мәрҗан», «Исме әгъзам» кебек догаларның аерым кәгазьгә язган күчермәләре, шулай ук мөнәҗәтләр язылган аерым битләр сакланып калган. Каты авырудан тернәкләнеп килүче Рушания апаның кызы Флёра Назгар кызы (1969 елгы) Тахтарова әбиләре Әбидә Әхмәтҗан кызы Иртугановадан (Кушкин әби) калган әлеге мирасның өйләрендә бик кадерләп саклануы турында сөйләде.

Пенза өлкәсендәге татар авыллары үзләре тәрбияләгән атаклы шәхесләр аша да билгеле. Һәр авыл үзенең күренекле нәсел вәкилләрен яхшы белә. Алдагы Мачали авылында (Каменка районы) без язучы, мөгаллим Муса Акъегетзадә (1864–1923), 1939–1941 елларда Институтыбызның директоры булып эшләгән Хәсән Габдрахман улы Шабанов (1901–1956) эзләре буйлап йөрдек. Мачалидә яшәүче Муса Лотфулла улы (1939 елгы) һәм Сания Абдул кызы (1948) Макуевларда 25 ел авылда мулла булып торган Лотфулла хәзрәттән калган (1902 елгы) «Алты бармак китабы»на (Казан, 1899), «Рисаләи фарзы гайн һәм дәгъвәт» (Казан, 1903), «Рисаләи Тәүхид» (Казан, 1904), «Бәдәвам» (Казан, 1906), Һ. Максудиның «Гакаид»ы (Казан, 1915), «Шәраит әл-иман» (Казан, 1917), «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка

шәриф догалар» (Казан, 1917) кебек дини эчтәлекле китапларга, кульязма «Манара бәете»нә юлыктык.

Авыл халкында сакланган «Кәлам шәриф тәфсире» (1899), «Кыйссел-әнбия», «Мохтәсар тарих ислам» (Рәшит Ибраһим улы Уразгильдеевта (1960 елгы), «Мөхәммәдия», «Мәүлид ән-нәби галәйһиссәлам» кульязмасы (Фәридә Сабирҗан кызы Акҗигитовада), «Һәза догаи Мәрҗан» (Сафия Мөхәммәт кызы Погодинада (1934 елгы) кебек дини китаплар Мачали авылында электә нинди китаплар укылганлыкны раслаучы дәлилләр иде. Алар арасында «Гарәп теле дәреслеге», «Сарфы гарәби» (Казан, 1898), «Мөгаллиме нәхү лисане әл-гарәб» (Казан, 1903) кебек чыганакларның да очравы халыкның гарәп телен өйрәнүгә омтылышы булуын күрсәтә.

Гарәп язуындагы кәгазьләргә халыкта изге итеп карау сизелеп тора. Аларның илаһи көченә ышанып, хәтта елаган баланың мендәр астына да гарәп язулы китап битләре тыга идек, дип сөйләделәр Мачалидә. Бу ышану, үз чиратында, китапларның таркалуына китергән.

«Алты авыл»ның чираттагысы Кабылкин (Каменка районы) авылы үзенең төзеклелеге, зурлыгы белән аерылып тора. Авыл имамы Руслан Хәмзә улы Тинчурин сүзләренә караганда, авылда 1942 елда бик каты янгын булган. Шул вакытта бик күп китаплар янып беткән. Кайбер кешеләр үзләрендә калган иске китапларны саклау өчен мәчеткә тапшырганнар. Мәчеттә сакланган басма китаплар арасында да «Кәлам шәриф тәфсире» (1889), Һ. Максудиның «Шәригать исламиянең әхкям гамәлиясе»нән (С.-Петербург, 1899) башкалары «Мөхәммәдия», «Рисаләи Газизә», «Тәгълим әс-салят тәрҗемәсе», «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Нәвадир тәрҗемәсе» китапларыннан калган башы-ахыры булмаган тарихи истәлекләр генә иде. Араларында «Китабы Устуани» кебек янгын шаһитлары да очрады.

Рамил Камил улы (1979 елгы) белән Әлфия Заһидулла кызы (1978 елгы) Кудряковлар авылда бабалары – 1896 еллардан мулла булып торган Гыйниятулла хәзрәт, 1906 елдан мулла булган аның улы Ибраһим хәзрәттән калган иске китапларны, аларның кулы белән язылган һәр кәгазьне кадерләп саклаганнар. Әлеге язма ядкәрләр «Китабы Бакырган», «Тәгъбирнамәи йәнабигъ тәрҗемәсе» (С.-Петербург, 1896), «Рисалә әш-Шафия» (Казан, 1901), «Рәднамә» (Казан, 1908), Шәһид Гауниның «Фән әт-тәҗвид»е (Казан, 1912), «Көйле иман» (мәктәп балаларына) (Казан, 1915) «Мәҗмәгъ әддәгъвәт», «Мәвакыйф» кебек нигездә дини эчтәлектәге басма китаплардан гыйбарәт. Арада сакланган «Эш һәм белем» китабының аерым битләре аларның хуҗаларының дөньяви белемнәр белән кызыксынганлыклары турында сөйли. Кайда гына булсак та, иң мөһим табыш, әлбәттә, кульязмалар була. Кудряковларда да, борынгы чорларга караган булмаса да, кульязма дәфтәр табылуга бик тә сөендек. Анда шулай ук мөнәҗәтләр, дини эчтәлектәге шигырьләр язылган.

Белинский районына керүче Кутеевка (Качкару) авылы да – «Алты авыл»ның берсе. Тарихта Төрек армиясе генералы булып

танылган Шакир пашаның туган авылы белән танышуым нәкъ менә Яваевлардан башланды [Мөбәрәкшина]. Фируша Абделкадыйр улы (1950 елгы) белән Сафия Әхмәтҗан кызы (1953 елгы) Яваевларда Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улы Яваев нәселеннән булган Абделкадыйр мулладан калган иске китаплар барланды. Басма «Кәлам шәриф тәфсире» (Петербург, 1898), «Тәсһил әл-бәян фи тәфсир әл-Коръән» (Казан, 1910), Габдулла Мөхәммәдфәезнең «Мохтәсар гыйльме халь»е (Казан, 1908), «Шөрут әс-салят» (Казан, 1911), Һ. Максудиның «Тәһарәт (Гыйбадәте исламия мәҗмугасының икенче сыйныф шәкертләре өчен)» (Казан, 1911) китаплары арасында сакланган кулъязма дәфтәр бигрәк тә игътибарны җәлеп итте. Анда язылган «Манара бәете», «Суга барган ана бәете» һ. б. шигырьләр безнең фондларыбызда урын алды.

Шушы авылда туып, бүгенге көндә Пенза шәһәрендә яшәүче, Шакир пашаның турыдан-туры нәсел дәвамчысы Тумеркина Фирдәүс Казыйм кызы (1961 елгы) белән танышу аеруча кызыклы булды. Ул, күп еллар буе мәгълүмат туплап, Шакир паша турында аерым китап та әзерләп бастырган («По следам Шакир-паши», 2021). Бик кызыксынучан Фирдәүс ханым этисенең әнисе Мөхлисә әбидән (1898–1980) калган иске китапларны үзендә бик кадерләп саклый. Алар – «Кыйссасел-әнбия» (Казан, 1899), «Кырык хәдис» (Казан, 1889), «Һәза китаб дәкаикыль әхбар» (Казан, 1900), «Әнварел-гашыйкыйн» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» (Казан, 1907), Гәрәй Арслановның «Табышмаклар»ы (Казан, 1910), «Тәгъбирнамә» (Казан, 1886, 1917) кебек басма китаплар. Шулай ук үләннәр белән дәвалау турындагы аерым кулъязмалар да бар.

Халыкта сакланган «Рәднамә» (Казан, 1909), «Мәҗмәгъ әддәгъвәт», «Хизбел бәхер», «Дәкаикыль әхбар тәрҗемәсе», «Нәвадир тәрҗемәсе», (Багдалова Наҗия Кәрибулла кызында (1956 елгы) кебек китапларның исемнәре генә дә бу төбәктәге татарларның дин-белемгә омтылышлары зур булуы турында сөйли.

Тарихи «Алты авыл»ның соңгысы Решетин авылы (Пачелма районы) иде. Авыл мәчетендә элеккеге имам Хансиверов Нязиф Исхак улыннан калган, шулай ук шушы авыл кешеләре Казиев Айнулла Мәүледбирде улы, Бариев Сәлимҗан Фәтхулла улы, Максутов Әхмәтҗан, хәзерге имамы Ирфан Әнвар улы Тепаевның әбисе Тепаева Факия Әхмәтҗан кызы тарафыннан тапшырылган шактый гына китаплар булуы ачыкланды.

Биредә ислам дөньясында билгеле булган «Мөхәммәдия», «Мең дә бер хәдис», «Ходай Тәгаләнең мең дә бер исемнәре хасиятләре берлән» (Казан, 1883), «Җәннәтел әсма» (С.-Петербург, 1903), «Китабе хәзрәт Йосыф галәйһиссәлам» (Казан, 1909), «Шөрут әс-салят тәрҗемәсе» (Казан, 1910), «Мөнбиһат тәрҗемәсе» (Казан, 1915) кебек дини китаплар белән бергә дөньяви белем бирә торганнары да бар. Мәсәлән, «Татарча уку» китабы халыкның әдәбиятка омтылышы турында сөйләсә, «Умарталар турында китап» авылда бал кортлары

белән кызыксынучылар булган дигән фикерләр уята. Татар халкының бөек шагыйре «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи асаре» китабы аеруча игътибарга лаек. Кызганычка, китапның башындагы һәм ахыргы берничә бите ертылган, бер карау белән генә китапның ничәнче елгы икәнен әйтеп булмый. Әлеге китап 1914 һәм 1918 елларда басылган. Китапта рәсемнәр булмауны исәпкә алып, аны 1918 елгы басма дип фаразларга мөмкин.

Китаплар барысы да басма. Шулай да әлеге материаллар арасында безнең өчен әһәмиятле булган кульязмалар да очрады. Алар – васыятьнамә һәм ике дәфтәрдә язылган мөнәҗәтләр (берсен 2014 елның декабрендә авылдагы Нурҗиһан апа бүләк иткән).

Мәчеттә саклана торган китаплардан гына чыгып та, авыл халкы элек-электән бик дини булган дияргә мөмкин. Коръән китапларын исәпкә алмаганда, анда 30 дан артык төрле эчтәлектәге китап барланды. Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» (5 нөсхә), Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (2 нөсхә), «Тәфсире һәфтияк» (5 нөсхә) китапларының берничә нөсхәдә булулары электә аларның халык арасында еш укылганлыгы турында сөйли. «Ислам мәҗәлләсе» («Ислам җыентыгы», елы билгесез, 9–10 саннар) журналының битләре дә бу җирлектәге халыкның бик кызыксынучан һәм дин-белемгә омтылучан булганлыгын күрсәтә.

Авылда яшәүче Казеева Сания Әхмәтҗан кызы (1936 елда туган) әтисе Бариев Әхмәтҗан Фәтхулла улыннан калган «Әнварел-гашыйкын», «Тәрҗемәи мохтәсарел викая» китапларын кадерләп саклаган. Сания апаның сүзләренә караганда, әтисе бу китапларны бик яратып укыган һәм үзенең улларының берсенә Әнвәр, ягъни «Нурлы» дип, исем дә кушкан.

«Алты авыл» божрасыннан чыгып, Пенза өлкәсендәге татар авылларын барлауны дәвам иттек. Чираттагы Ятмис (Кочалейка, Каменка районы) авылында, нигездә, дини эчтәлекле «Мөхәммәдия», «Тәфсире һәфтияк» (1897), «Тәрҗемә әл-мәсаил вә җаваб әс-саил» (С.-Петербург, 1897), «Мохтәсар иман» (С.-Петербург, 1904) (имам хатип Хәмзә Юныс улы Еникеевта), «Мөхәммәдия» (Казан, 1903), «Рисаләтел сигез җәннәт», «Рисаләи Газизә», «Һәфтияк тәфсире», «Алты бармак», «Гакаид исламия» (Казан, 1899), «Фәзаилеш шөһүр» (мәчеттә), «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Тәкый гаҗәб» (Абүбикарова Разия Шакир кызында (1948 елгы), С. Бикбулатның «Дин дәресләре» (Казан, 1918), «Әнварел гашыйкыйн» (Еникеева Разыя Ибраһим кызында (1933 елгы) китаплары сакланганлыгы ачыкланды.

Пачелма районының Татаро-Никольское авылы без булган авыллар белән чагыштырганда күпкә кечкенә булса да, сакланып калган китаплар саны буенча бер дә алардан калышмый. Авылда яшәүче 150 ләп кешенең яртысыннан кимрәге генә татарлар икән. Мөнәвәрә Али кызы Маминада (1946 елгы) каенатасы Усман Йосыф улы (1916–1972) белән каенанасы Латыйфа Идиятулла кызыннан (1908–1973) калган кадерләп төрелгән төргәктән кайчандыр болар «Мөхәммәдия»,

«Әхлак рисаләсе», «Һәфтияк шәриф», «Китабел-ләбаб», «Рисаләи нурнамә» (Казан, 1901), «Кыйраәте җәдидә», «Бәдел-мәгариф», «Китаб мөстәтаб. Рәүнәкыль ислам», «Абдәст вә намаз рисаләсе» (Казан, 1899), «Сөбател-гаҗизин», «Татарча уку», «Тәзкия әт-табигать» китаплары булганлыгын дәлилли торган бик күпне күргән аерым басма китап битләре чыкты. Араларында «Әдәбле улмак»ка өйрәтә торган бер кулъязма да бар иде.

Мәрьям Зиннур кызы Мамина (1949 елгы) да авылда мулла булып торган каенатасы Гомәр хәзрәттән калган мирас белән белән таныштырды. «Корбан рисаләсе» (С.-Петербург, 1899), «Тәфсире һәфтияк» (Казан, 1900), «Гыйбадәте исламия»нең дүртенче җөзьэ (Казан, 1904), «Гасры сәгадәт», Г.Барудиның «Сөаль вә җаваплы бәдел мәгариф»е (Казан, 1908, 1911), «Китабы Устуани», «Китабы гыйльме халь» (тәһарәт кыйсьме, 3 нче җөзьэ) (Казан, 1915), Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, «Фәзаилеш шөһүр», «Намаз нигезләре», «Кыйссасел-әнбия тәрҗемәсе», «Мөгаллимел-гыйбадәт», «Мөгаллиме әүвәл», «Мөгаллиме сани яки әлифбаи гарәби» (Казан, 1914), «Дөнья» (гомуми география дәресләре) (Казан, 1918), «Гокуд саляс», «Хәвас әсма Аллаһ әл-хөснә» (С.-Петербург, 1895), «Тәрҗемәтел әнисел җәлис», «Сөбател гаҗизин» китапларын туплаган исемлек шактый зур булды. Ләкин аларның сакланыш дәрәҗәләре бик түбән иде.

Аралашкан кешеләремнең барысы да Мамин фамилияле булуы игътибарны җәлеп итте. Тарихи чыганакларга караганда, рус дәүләтенең татарларны чукындыруыннан качып, бу якларга Рязань өлкәсеннән татар морзалары килгәннәр. Татар Никольскоесы авылында татар кенәзләре Маминнар яшәгән. 1917 елда биредә 177 хуҗалыкның 127 сендә Маминнар торган. Шулай итеп, мондагы татарлар әле дә үзләренең кенәз-морза бабаларының тамырларын саклыйлар [Татар Никольскоесы].

Спас районына керүче Шалдавыч авылы мәчетендә «Коръән» китапларыннан тыш «Мөхәммәдия» (Казан, 1902), «Китабе сөлләмел голүм» (Казан, 1887), «Догаи мөстәҗаб» (Казан, 1913), «Җәмигъ әл-хөтеб» (Казан, 1910), «Мәҗалисеш шөһүр», «Һәфтияк шәриф», «Шәраит әл-иман» (Казан, 1903), «Бинаи ислам», «Хәләби тәрҗемәсе» китаплары барланды. Шундый кечкенә генә авылда да Рәйсә Нәҗип кызы Курамшина (1938 елгы), Заһидулла Каюм улы Юлгушев (1939 елгы) («Алты бармак», «Мөхәммәдия», «Китабел әнмүзәҗ», «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка шәриф догалар» (Казан, 1909) кебек борынгы ядкәрләрне кадерләп саклаучы кешеләрнең булуы күңелгә рухи ләззәт бирә.

Пенза өлкәсендә алып барылган фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә гарәп хәрефендә татар һәм гарәп телләрендәге барлыгы 140 исемдәге басма китап теркәлде. Кызганычка, алар, нигездә, башы-ахыры булмаган китаплар.

Бүгенге көндә гарәп хәрефле кулъязма китап табу шактый авыр. Без йөргән татар авылларында да аларның булмавы гаҗәп түгел.

Әлеге төбәктә бик еш очраган Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, Насретдин Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия»се («Пәйгамбәрләр тарихлары»), Әхмәт Биҗанның «Әнварел-гашыйкыйн» («Гашыйклар нуры»), Таҗетдин Ялчыгылның «Рисаләи-Газизә»се, «Бакырган китабы» кебек әдәби ядкәрләр күп еллар буена мәдрәсәләрдә дәреслекләр сыйфатында файдаланылып килгәннәр. Алар, әдәбилек белән бергә дини-дөньяви гыйлемне дә үзләренә сыйдырганнар. «Фән һәм әдәбият бергә кушылу, синтетик бөтен хасил итү аркасында ул китаплар гасырлар буена практик әһәмиятләрен югалтмаганнар, укучыларда эстетик зәвык белән беррәттән, аларга гыйльми информация дә биреп, аң үсешен тәрбияләү өчен дә хезмәт иткәннәр» [Яхин, б. 4]. Һәм халык арасында киң кулланылышта йөргәннәр. Һәр авылда бу китапларның очравы тагын бер кат аларның яратылып укылулары һәм бик полуляр булганлыклары турында сөйли.

Әлбәттә, иске китапларга сакчыл карашлы кешеләрнең күп булуы – куанычлы хәл. Әби-бабайлардан калган рухи мирасны шулай кадерләп саклау үзенә күрә бер тәрбия чарасы да булып тора. Киләчәктә бу авылларда гарәп язулы китапларны укучылар булырына ышанасы килә.

Гомумән, хөрмәткә лаек халык яши Пенза өлкәсендә. Алар үзләренең бик гади, ачык йөзле һәм кунакчыл булулары белән күңелгә кереп калдылар.

**Әдәбият**

*Зюзин Ф.М.* История татар Пензенского края. Т. 1. URL: https://clck.ru/3DKHjY (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Зюзин Ф.М.* История татар Пензенского края. Т. 1. URL: https://fictionbook.ru/author/fattih_muhomyatovich_zyuzin/istoriya_tatar_penzenskogo_kraya_tom_1/read_online.html?page=3 (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Мөбәрәкшина Зилә.* Төркиядәге татар генералы Шакир пашаның туганы: Имамның сүзеннән чыгып китап яздым. URL: https://tatar-inform.tatar/news/torkiyadage-tatar-generaly-sakir-pasanyn-tugany-imamnyn-suzennan-cygyp-kitap-yazdym-5860717 (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Саляев Е.И.* Татары в истории Пензенского края // Гуманитарные науки. 2007. № 4. С. 122–126.

Татар Никольскоесы. URL: https://clck.ru/3DKJBd (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 392 б.

*Яхин Ф.З.* Борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты: Югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен дәреслек-кулланма. Казан: Раннур. 2011. 188 б.

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре*